ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2021 г. Заинск № 556

**«Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Гамәлдән чыккан дип танырга:
2.1. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 1166 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;
2.2. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 1166 номерлы Зәй муниципаль районы

Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 10 декабрендәге 1819 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

2.3. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 1166 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 июнендәге 248 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Р. Исламова
3-47-87